**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**

**Чалпы авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

Чалпы авылы № 102-1 «08» май 2014 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турындагы нигезләмәне һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге Советы нигезендә

Карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турындагы нигезләмәне һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Законлылык һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.Т.Ибраһимов